| | |
|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**Об утверждении Положения об Управлении Раиса Республики Татарстан по работе с обращениями граждан**

В соответствии с Указом Президента Республики Татарстан от 4 февраля 2023 года № УП-68 «Об Администрации Главы (Раиса) Республики Татарстан» **постановляю:**

1. Утвердить прилагаемое Положение об Управлении Раиса Республики Татарстан по работе с обращениями граждан.

2. Признать утратившими силу:

Указ Президента Республики Татарстан от 18 мая 2006 года № УП-180 «Об утверждении Положения об Управлении по работе с обращениями граждан Президента Республики Татарстан»;

Указ Президента Республики Татарстан от 27 декабря 2013 года № УП-1292 «О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об утверждении Положения об Управлении по работе с обращениями граждан Президента Республики Татарстан».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** — **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
16 мая 2023 года
№ 303

Утверждено
Указом Раиса
Республики Татарстан

от «16» мая 2023 года

№ 303

**Положение**
**об Управлении Раиса Республики Татарстан по работе**
**с обращениями граждан**

I. Общие положения

1. Управление Раиса Республики Татарстан по работе с обращениями граждан (далее также – Управление) является структурным подразделением Администрации Раиса Республики Татарстан.

2. Управление образовано в целях обеспечения объективного, всестороннего и своевременного рассмотрения обращений граждан, объединений граждан, в том числе юридических лиц (далее – обращения граждан), адресованных Раису Республики Татарстан, Премьер-министру Республики Татарстан, Администрации Раиса Республики Татарстан, Кабинету Министров Республики Татарстан и Аппарату Кабинета Министров Республики Татарстан.

3. Управление в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, федеральными конституционными законами, федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, законами Республики Татарстан, указами и распоряжениями Раиса Республики Татарстан, Положением об Администрации Раиса Республики Татарстан, нормативными правовыми актами Республики Татарстан, распоряжениями Руководителя Администрации Раиса Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

4. Управление непосредственно подчиняется Раису Республики Татарстан и Руководителю Администрации Раиса Республики Татарстан.

5. Положение об Управлении утверждается Раисом Республики Татарстан.

II. Основные задачи Управления

6. Основными задачами Управления являются:

обеспечение объективного, всестороннего и своевременного рассмотрения обращений граждан, адресованных Раису Республики

Татарстан, Премьер-министру Республики Татарстан, Администрации Раиса Республики Татарстан, Кабинету Министров Республики Татарстан и Аппарату Кабинета Министров Республики Татарстан, предоставление письменных ответов на них в порядке, установленном законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан;

обеспечение контроля за своевременным рассмотрением государственными органами Республики Татарстан, органами местного самоуправления и их должностными лицами поручений Раиса Республики Татарстан, Премьер-министра Республики Татарстан, Руководителя Администрации Раиса Республики Татарстан и заместителей Премьер-министра Республики Татарстан по обращениям граждан;

проведение информационно-аналитической работы с обращениями граждан;

проведение разъяснительной работы с населением по вопросам реализации гражданами Российской Федерации (далее также – граждане) закрепленного за ними Конституцией Российской Федерации права на обращение в государственные органы и органы местного самоуправления.

## III. Основные функции Управления

7. Основными функциями Управления являются:

регистрация, учет и первичная обработка поступивших обращений граждан, адресованных Раису Республики Татарстан, Премьер-министру Республики Татарстан, Администрации Раиса Республики Татарстан, Кабинету Министров Республики Татарстан и Аппарату Кабинета Министров Республики Татарстан, в системе межведомственного электронного документооборота, единой межведомственной системе электронного документооборота Республики Татарстан;

подготовка информационно-справочных материалов по обращениям граждан для Раиса Республики Татарстан, Премьер-министра Республики Татарстан, руководителей Администрации Раиса Республики Татарстан и Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан;

направление обращений граждан на рассмотрение в государственные органы Республики Татарстан, федеральные государственные органы, их территориальные органы, органы местного самоуправления, организации, должностным лицам в соответствии с их компетенцией;

подготовка предложений по решению поставленных в обращениях граждан вопросов;

уведомление граждан, объединений граждан, в том числе юридических лиц, о направлении их обращений на рассмотрение в другой государственный орган, орган местного самоуправления или иному должностному лицу в соответствии с их компетенцией;

организация проверки фактов, изложенных в обращениях граждан, в том числе с выездом на место;

осуществление количественного и качественного анализа обращений граждан, подготовка информационных, аналитических и статистических материалов, оперативное и систематическое информирование Раиса Республики Татарстан, Премьер-министра Республики Татарстан, руководителей Администрации Раиса Республики Татарстан и Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан о результатах проведенного анализа;

подготовка проектов поручений Раиса Республики Татарстан, Премьер-министра Республики Татарстан, Руководителя Администрации Раиса Республики Татарстан и заместителей Премьер-министра Республики Татарстан по поступившим обращениям граждан;

анализ представленных исполнителями ответов на предмет полноты исполнения поручений по обращениям граждан, правильности их оформления и снятие с контроля исполненных документов;

согласование в пределах компетенции Управления технических заданий на разработку и совершенствование информационных, документационных технологий и участие в приемке этих технологий;

обеспечение по поручению Раиса Республики Татарстан, Премьер-министра Республики Татарстан, руководителей Администрации Раиса Республики Татарстан и Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан проверки соблюдения законодательства Российской Федерации и законодательства Республики Татарстан при рассмотрении обращений граждан в государственных органах Республики Татарстан, органах местного самоуправления, принятия мер по устранению выявленных нарушений;

изучение и обобщение опыта работы с обращениями граждан в государственных органах Республики Татарстан и органах местного самоуправления;

оказание методической и консультативной помощи в организации работы с обращениями граждан в государственных органах Республики Татарстан и органах местного самоуправления;

организация личного приема граждан Раисом Республики Татарстан, Премьер-министром Республики Татарстан, а также руководителями Администрации Раиса Республики Татарстан и Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан, руководителями структурных подразделений Администрации Раиса Республики Татарстан и Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан;

ведение приема и консультирование граждан по вопросам реализации гражданами закрепленного за ними Конституцией Российской Федерации права на обращение в государственные органы и органы местного самоуправления;

подготовка проектов нормативных правовых актов и методических материалов по вопросам организации работы с обращениями граждан;

участие в подготовке материалов и оформлении решений, принимаемых на совещаниях, проводимых Раисом Республики Татарстан, Премьер-министром Республики Татарстан, руководителями Администрации

Раиса Республики Татарстан и Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан по вопросам, связанным с рассмотрением обращений граждан;

формирование дел по рассмотренным обращениям граждан в установленном порядке, обеспечение их сохранности.

Управление осуществляет также иные функции по поручениям Раиса Республики Татарстан, Руководителя Администрации Раиса Республики Татарстан.

## IV. Права Управления

8. Управление для осуществления своих задач и функций имеет право:

направлять обращения граждан на рассмотрение в государственные органы Республики Татарстан, федеральные государственные органы, их территориальные органы, органы местного самоуправления, организации, должностным лицам в соответствии с их компетенцией;

запрашивать и получать в установленном порядке от государственных органов Республики Татарстан, федеральных государственных органов, их территориальных органов, органов местного самоуправления, организаций и их должностных лиц сведения, необходимые для обеспечения рассмотрения обращений граждан;

вносить предложения Руководителю Администрации Раиса Республики Татарстан по совершенствованию работы с письменными обращениями граждан, организации личного приема граждан, совершенствованию делопроизводства в Администрации Раиса Республики Татарстан;

привлекать по согласованию с Руководителем Администрации Раиса Республики Татарстан в установленном порядке для осуществления отдельных направлений деятельности Управления представителей научных организаций, ученых и специалистов;

пользоваться в установленном порядке информацией, содержащейся в государственных информационных системах Республики Татарстан;

приглашать обратившихся граждан для личной беседы в целях уточнения предмета обращения;

запрашивать в установленном порядке, в том числе в электронной форме, дополнительные материалы и объяснения у обратившихся граждан, объединений граждан, в том числе юридических лиц;

возвращать государственным органам, органам местного самоуправления и их должностным лицам представленные с нарушениями установленного порядка документы для доработки и оформления в соответствии с установленными требованиями.

## V. Взаимодействие Управления

9. Управление при реализации возложенных на него функций взаимодействует с Аппаратом Государственного Совета Республики Татарстан, Аппаратом Кабинета Министров Республики Татарстан, иными

государственными органами Республики Татарстан, федеральными государственными органами и их территориальными органами, органами местного самоуправления, организациями и гражданами, а также со всеми структурными подразделениями и должностными лицами Администрации Раиса Республики Татарстан.

## VI. Ответственность

10. Работники Управления несут ответственность за выполнение возложенных на них обязанностей в соответствии с утверждаемыми Руководителем Администрации Раиса Республики Татарстан должностными регламентами.

## VII. Организация деятельности Управления

11. Структура и штатная численность Управления утверждаются Раисом Республики Татарстан.

12. Руководство деятельностью Управления осуществляет начальник Управления Раиса Республики Татарстан по работе с обращениями граждан (далее – начальник Управления), который назначается на должность и освобождается от должности указом Раиса Республики Татарстан.

13. Начальник Управления:

осуществляет непосредственное руководство деятельностью Управления, обеспечивает решение возложенных на него задач, несет персональную ответственность за эффективное выполнение функций Управлением, состояние исполнительской и служебной дисциплины в Управлении;

участвует в совещаниях у Раиса Республики Татарстан, в заседаниях Кабинета Министров Республики Татарстан, государственных органов Республики Татарстан, а также органов, образуемых Раисом Республики Татарстан, при рассмотрении вопросов, отнесенных к компетенции Управления, направляет в установленном порядке для участия в совещаниях представителей Управления;

подписывает и визирует служебные документы в пределах своих полномочий;

распределяет должностные обязанности между работниками Управления и представляет на утверждение Руководителю Администрации Раиса Республики Татарстан их должностные регламенты;

вносит предложения Руководителю Администрации Раиса Республики Татарстан о повышении квалификации работников Управления, применении к ним мер поощрения и дисциплинарного взыскания;

вносит предложения Руководителю Администрации Раиса Республики Татарстан о назначении на должность либо освобождении от должности, а также командировании работников Управления.

14. В период временного отсутствия начальника Управления его обязанности исполняет заместитель начальника Управления либо иное уполномоченное должностное лицо Управления.

15. Работники Управления назначаются на должность и освобождаются от должности Руководителем Администрации Раиса Республики Татарстан по представлению начальника Управления.

___________

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисенең Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 18 маендагы ПУ-180 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 27 декабрендәге ПУ-1292 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 16 май
№ 303

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «16» маендагы
303 номерлы Указы
белән расланды

**Татарстан Республикасы Рәисенең**
**Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе турында**
**нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе (алга таба шулай ук – Идарә) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.

2. Идарә гражданнарның, гражданнар берләшмәләренең, шул исәптән юридик затларның Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Премьер-министрына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына объектив, бөтен яклап һәм үз вакытында карауны тәэмин итү максатларында төзелде.

3. Идарә үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турындагы нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Идарә турыдан-туры Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә буйсына.

5. Идарә турында нигезләмәне Татарстан Республикасы Рәисе раслый.

II. Идарәнең төп бурычлары

6. Идарәнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

гражданнарның Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Премьер-министрына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына җибәрелгән мөрәҗәгатьләрен объектив, бөтен яклап һәм үз вакытында карауны тәэмин итү, аларга Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә язма җаваплар бирү;

Татарстан Республикасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Премьер-министрының, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларының гражданнарның мөрәҗәгатьләре буенча йөкләмәләренең Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан үз вакытында каралуына контрольне тәэмин итү;

гражданнар мөрәҗәгатьләре белән мәгълүмати-аналитик эш уздыру;

Россия Федерациясе гражданнары (алга таба шулай ук – гражданнар) тарафыннан аларның дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итүгә кагылышлы Россия Федерациясе Конституциясендә каралган хокукларын гамәлгә ашыруы мәсьәләләре буенча халыкка аңлату эше алып бару.

## III. Идарәнең төп функцияләре

7. Идарәнең төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

гражданнарның Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Премьер-министрына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына җибәрелгән мөрәҗәгатьләрен Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше ведомствоара системасында, электрон документлар әйләнеше ведомствоара бердәм системасында теркәү, исәпкә алу һәм беренчел эшкәртү;

гражданнарның мөрәҗәгатьләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчеләре өчен мәгълүмати-белешмәлек материаллар әзерләү;

гражданнар мөрәҗәгатьләрен вәкаләтләренә карап, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, федераль дәүләт органнарына, аларның территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга, вазыйфаи затларга юллау;

гражданнар мөрәҗәгатьләрендә куелган мәсьәләләрне хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

гражданнарга, гражданнар берләшмәләренә, шул исәптән юридик затларга, аларның мөрәҗәгатьләренең вәкаләтләренә карап, башка дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә башка вазыйфаи затка карау өчен юллануы турында хәбәр итү;

гражданнар мөрәҗәгатьләрендә бәян ителгән фактларны, шул исәптән урыннарга чыгып та тикшерүне оештыру;

гражданнарның мөрәҗәгатьләрен сан һәм сыйфат ягыннан анализлау, мәгълүмати, аналитик һәм статистик материаллар әзерләү, Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Премьер-министрына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе һәм Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчеләренә уздырылган анализ йомгаклары турында оператив һәм системалы рәвештә мәгълүмат бирү;

гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары йөкләмәләре проектларын әзерләү;

башкаручыларның гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча йөкләмәләрнең тулысынча үтәлүенә, аларның дөрес рәсмиләштерелүенә һәм башкарылган документларны контрольдән алуга кагылышлы җавапларын анализлау;

Идарә вәкаләтләре чикләрендә мәгълүмати, документаль технологияләрне эшләү һәм камилләштерүгә техник биремнәрне килештерү һәм бу технологияләрне кабул итүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчеләре йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасының дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карага нда Россия Федерациясе законнарының һәм Татарстан Республикасы законнарының үтәлүен тикшерүне, ачыкланган хокук бозуларны бетерү өчен чаралар күрүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәҗрибәсен өйрәнү һәм гомумиләштерү;

Татарстан Республикасы дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүне оештыруда методик һәм консультатив ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Премьер-министрының, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчеләренең, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты структур бүлекчәләре җитәкчеләренең гражданнарны шәхсән кабул итүен оештыру;

гражданнар тарафыннан аларның дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итүгә кагылышлы Россия Федерациясе Конституциясендә каралган хокукын гамәлгә ашыруы мәсьәләләре буенча гражданнарны кабул итүне алып бару һәм аларга консультацияләр бирү;

гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүне оештыру мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар һәм методик материаллар проектларын әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчеләре уздырган киңәшмәләрдә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау белән бәйле

материалларны әзерләүдә һәм кабул ителә торган карарларны рәсмиләштерүдә катнашу;

билгеләнгән тәртиптә гражданнарның каралган мөрәҗәгатьләре буенча эш кәгазьләрен формалаштыру, аларның саклануын тәэмин итү.

Идарә шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләмәләре буенча башка функцияләр дә башкара.

## IV. Идарәнең хокуклары

8. Үзенең бурычларын һәм функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Идарә түбәндәгеләргә хокуклы:

гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау өчен, вәкаләтләренә карап, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, федераль дәүләт органнарына, аларның территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга, вазыйфаи затларга юлларга;

Татарстан Республикасы дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан, аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм аларның вазыйфаи затларыннан билгеләнгән тәртиптә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карауны тәэмин итү өчен кирәкле белешмәләр соратырга һәм алырга;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә гражданнарның язма мөрәҗәгатьләре белән эшләүне камилләштерү, гражданнарны шәхсән кабул итүне оештыру, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә эш башкаруны камилләштерү буенча тәкъдимнәр бирергә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән килештереп, Идарә эшчәнлегенең аерым юнәлешләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тәртиптә фәнни оешмалар вәкилләрен, галимнәрне һәм белгечләрне җәлеп итәргә;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати системаларындагы мәгълүматлардан файдаланырга;

мөрәҗәгатьнең эчтәлегенә төгәллек кертү максатларында мөрәҗәгать иткән гражданнарны шәхси әңгәмәгә чакырырга;

мөрәҗәгать иткән гражданнардан, гражданнар берләшмәләреннән, шул исәптән юридик затлардан билгеләнгән тәртиптә өстәмә материаллар һәм аңлатмалар, шул исәптән электрон формада да, соратып алырга;

билгеләнгән тәртипне үтәмичә тапшырылган документларны дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына билгеләнгән таләпләр нигезендә эшләп бетерү һәм рәсмиләштерү өчен кире кайтарырга.

## V. Идарәнең хезмәттәшлек итү даирәсе

9. Үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашырганда Идарә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм гражданнар, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең барлык структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

10. Идарә хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар нигезендә үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы.

## VII. Идарә эшчәнлеген оештыру

11. Идарәнең структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

12. Идарәгә Татарстан Республикасы Рәисе указы нигезендә вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган Татарстан Республикасы Рәисенең Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе башлыгы (алга таба – Идарә башлыгы) җитәкчелек итә.

13. Идарә башлыгы:

Идарәнең эшчәнлегенә турыдан-туры җитәкчелек итә, аңа йөкләнгән бурычларның үтәлүен тәэмин итә, Идарәнең үз функцияләрен үтәве, Идарәдәге хезмәт дисциплинасы һәм бурычларны үтәү дисциплинасының торышы өчен шәхсән җаваплы була;

Татарстан Республикасы Рәисе уздырган киңәшмәләрдә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы дәүләт органнарын, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан оештырылган органнар утырышларында Идарә компетенциясенә карый торган мәсьәләләрне карап тикшерүдә катнаша, утырышта катнашу өчен билгеләнгән тәртиптә Идарә вәкилләрен җибәрә;

үз вәкаләтләре чикләрендә хезмәткә кагылышлы документларга кул куя һәм имза сала;

Идарә хезмәткәрләре арасында хезмәт бурычларын бүлә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә аларның вазыйфаи регламентларын раслауга кертә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Идарә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү, аларны бүләкләү һәм дисциплинар җәзага тарту турындагы тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Идарә хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләү яисә вазыйфадан азат итү, шулай ук аларны командировкага җибәрү турында тәкъдимнәр бирә.

14. Идарә башлыгы вакытлыча эш урынында булмаганда, аның вазыйфаларын Идарә башлыгы урынбасары яисә Идарәнең башка бер вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

15. Идарә хезмәткәрләре Идарә башлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.